

Ромодан районы Белозерье авылында Моселманнарнын Диния нәзарәте жәмгыятьләре очен Боек Жинvнен 80 еллыгына багышланган мәдәни-спорт чарасы узган. Республиканын торле авылларыннан берничә йоз катнашучыны хормәтле кунаклар сәламли, шул исәптән чарага махсус килгән Ботендонья татар конгрессы вәкиле Зофәр Вәлиәхмәтов.      Ел саен ярышларнын беренче олешендә интеллектуаль конкурста гаилә һәм никах темасы буенча сорауларга жавап кайтаралар. Белозерье авылыннан «Раджаб» жәмгыяте командасы ин дорес һәм тулы жаваплары белән беренчеләр булдылар.

Чаранын икенче олешендә йогерv, турникта тартылу, кул корәше, гер кvтәрv, таш ыргыту буенча спорт ярышлары vткән. Быел да ук ату конкурсында катнашучылар ярышкан. Киләчәктә дә бу милли корәш спорт торен vстерерг



ә уйлыйлар. Бу тордә жинvче - Белозерьедан Салих Бәширов. Ул, гадәттәгечә, батыр бvләген - тере бәрәнне жилкәсенә салды. Калган барлык жинvчеләр грамоталар һәм акчалата призлар белән бvләкләнделәр.

Чараны оештыручы Мордовия Республикасы моселманнары Диния нәзарәте vзәкләштерелгән дини оешмасынын рәисе, шәехРаиль хазрәт Асаинов vзенен ВКонтакте битедә болай ди: «Әлеге матур һәм эчтәлекле ярышлар бик кvнелле vтте. Кvпләр гаиләләре белән генә тvгел, ә берничә буын вәкилләре- бабалары, әтиләре һәм балалары килде. Оештырылган барлык ярышта яше-олысы катнашты. Мондый чаралар гаиләләрне ныгытуга хезмәт итә - гомергә калган унай хис-кичерешләр һәм истәлекләр кала. Рәхмәт барлык оештыручыларга, иганәчеләргә, волонтерларга.»

Чарада мотоцикл спорты һәм пычак ыргыту буенча мастер-класслар нәтижәле оештырылган. Халыкны тәмле пылау белән дә сыйлаганнар.